**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**Карары**

**№5404**
**22.10.2019**

Башкарма комитетның «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законның 65 маддәсенең 2 бүлеге, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 нче карарына (2014 елның 17 февралендәге 944 нче, 2015 елның 18 ноябрендәге 6571 нче, 2016 елның 29 апрелендәге 2159 нчы, 2017 елның 6 апрелендәге 1955 нче, 2018 елның 7 мартындагы 1180 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуладагы «Россия Федерациясе Бюджет кодексы» сүзләрен «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ санлы Федераль законының 65 маддәсенең 2 бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

2) мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенең 6 пунктындагы таблицаны түбәндәге эчтәлектәге алтынчы юл белән тулыландырырга:

«

| | | | |
|---|---|---|---|
| Яшәү минимумыннан түбән (күп балалы гаилә өчен) | 0 | 0 | 0 |

»

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин